**Межрегиональные предметные олимпиады КФУ**
**профиль «Татарский язык»**
**Заключительный этап**
**2021-2022 учебный год**
**11 класс**

**I. Сүзләрнең татарчага тәрҗемәсен языгыз /** Переведите слова на татарский язык (10 баллов. *За каждый правильный вариант по 1 баллу* ).

Девушка! *(обращение к незамужней девушке)*, знакомство, качество, прощение, терпение, совесть, вера, родословная, мероприятие, паук.

**II. *Фонема* һәм *транскрипция* терминнарына билгеләмә бирегез /** Дайте определение терминам *фонема* и *транскрипция* (10 баллов. *За каждый правильно данное определение по 5 баллов).*

**III. Сүзләрдәге хаталарны табыгыз һәм дөресләп языгыз /** Найдите ошибки в словах и напишите правильные варианты (10 баллов. *За каждый правильный ответ по 1 баллу*).

Утыннык, тоссыз, дулкыннану, күреңгән, комлак, гөмбагыш, сузыңкы, соңго, икеләммичә, баштубән.

**IV. Җөмләгә 1) синтаксик анализ ясагыз, 2) аның схемасын сызыгыз һәм 3) төрен билгеләгез** / Сделайте 1) синтаксический разбор предложения, 2) укажите схему и 3) определите тип предложения (15 баллов. За каждое задание по 5 баллов).

Галиәсгар байның подвалында яшәгән ятим малай егет булыр, үзе китаплар яза башлар. *(Ә.Фәйзи)*

**V. Тексттан гарәп-фарсы алынмаларын язып алыгыз. /** Выпишите из текста арабо-персидские заимствования. (10 баллов, по 1 баллу за каждый правильный пример)

Казан дәүләт университетына килеп, ике ел ана теле, милли әдәбият өлкәсендә гыйлем өсти Айнур. Аны безнең татар дөньясы төрле яктан кызыксындыра. Болар аның йөрәгендә генә түгел, фотограф-рәссам буларак, альбомнарында да урын ала. Үзенең нәселе чыккан Сергач якларын, Казан каласын һәм дә үзе туган Финляндия илендә яшәүче милләттәшләренең гореф-гадәтләрен, көнкүрешен киногa төшереп, бу фильмнарны Хельсинкиның үзәк телевидениесеннән күрсәтүгә ирешә ул. *(З. Шакирҗан)*

**VI. Җөмләдәге сүзләргә морфологик анализ ясагыз. /** Сделайте морфологический разбор слов в предложении (10 баллов. За каждый правильный ответ по 1 *баллу*.).

*Тургай сайраганда җир өстенә җиңелчә генә уйчан-моңсу бер тынлык җәелә. (Ә. Еники)*

**VII. Татар теле буенча дәреслекләр (хезмәтләр) авторы булган бер галим турында языгыз. Язмагызда 1) аның турында белгәннәрегезне, 2) хезмәтләренең исеме, 3) бер хезмәтенең эчтәлеге турында кыскача сөйләгез. /**Напишите об одном татарском ученом-языковеде, авторе учебников (трудов). Опишите 1) его деятельность, 2) названия основных трудов, 3) содержание одного из его трудов (15 баллов. Каждый вопрос оценивается 5 *баллами*).

**VIII. «Халыкныкы халыкта саклана. *(Әмирхан Еники)*» канатлы сүзен сез ничек аңлыйсыз? Шушы гыйбарәдә әйтелгән фикергә таянып, 70 сүздән ким булмаган инша языгыз. /«Всё народное хранится в народе» (Амирхан Еники)** Напишите, как вы

понимаете данный афоризм? Опираясь на это выражение, напишите сочинение (не менее из 70 слов) (20 баллов).